Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

3 март, 2021 ел № 53

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башка авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләре бирү турында» 2019 елның 24 октябрендәге 221 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга Питрәч муниципаль районы Советы Питрәч муниципаль районының Богородский Шигали, Кощаково авыл җирлекләре торак пунктларында буш җир кишәрлекләре булмауга бәйле рәвештә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башка авыл җирлекләре чикләрендә бирү турында» 2019 елның 24 октябрендәге 221 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Богородский, Шигали һәм Кощаково авыл җирлекләре территорияләрендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләрен сайлауга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге территориясендә бирелә.».

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов